КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 май г.Казань № 674

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсендәге су транспортында хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның кайбер категорияләренә социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсендәге су транспортында хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның кайбер категорияләренә социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарына (2005 ел, 17 ноябрь, 536 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2021 ел, 20 май, 351 нче, 2023 ел, 3 февраль, 94 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Шәһәр яны су транспортында йөрү хокукына ташламалы юл документы (билет) яисә утыру талоны ташламага хокукны раслый торган документ яки тиешле документта булган «Мәгълүмат алмашуның күпфункцияле сервисын булдыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 156-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән мәгълүмат алмашу буенча күпфункцияле сервистан файдаланып бирелгән белешмәләр күрсәтелгәндә шәһәр яны ташуларын гамәлгә ашыручы су транспорты предприятиеләре кассаларында сатып алына дип билгеләргә.

Әгәр мондый документтан белешмәләр мәгълүмат алмашуның күпфункцияле сервисыннан файдаланып бирелгән булса, ташламалы йөрү хокукын раслаучы документны тапшыруны таләп итү рөхсәт ителми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин